РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» 03 2026 ел №268

Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик кыйммәтләрен һәм гаилә әгъзалары милкендә булган яки ялгыз яшәүче гражданның 2026 елга салым салынырга тиешле мөлкәтенең чик бәясен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Ютазы муниципаль районы буенча торак мәйданының 1 квадрат метрының 2026 елның 1 кварталына уртача базар бәясен раслау турында»гы 04.02.2026 елның 93 санлы карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең һәм гаилә әгъзасы яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2026 елга салым салынырга тиешле мөлкәтнең бәясен «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган түбәндәге чик кыйммәтләрен һәр гаилә әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең чик кыйммәтләрен һәм мөлкәтнең билгеләү методикасы буенча әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы урынбасарына

социаль файдаланудагы торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә куйганда, әлеге карарга кушымтада күрсәтелгән керемнең максималь күләмен файдаланырга.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

С.Р. Сәетгәрәева
2-42-05

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
«12» 03 2026 ел № 268
Карарына кушымта

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2026 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләре**

| Гаилә әгъзалары саны (РС) | Торак урын бирү нормасы буенча базар бәясенең исәп күрсәткече (СЖ) | Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык керемнең чик күрсәткече |
|---|---|---|
| 1 | 964278 | 20436,68 |
| 2 | 1928556 | 20437,01 |
| 3 | 2892834 | 20437,12 |
| 4 | 3857112 | 20437,17 |
| 5 | 4821390 | 20437,21 |
| 6 | 5785668 | 20437,23 |
| 7 | 6749946 | 20437,24 |
| 8 | 7714224 | 20437,25 |
| 9 | 8678502 | 20437,26 |
| 10 | 9642780 | 20437,27 |